**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5219**
**06.08.2021**

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре бирү тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 статьясының 2 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре бирү тәртибе турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Муниципаль бюджет һәм автономияле учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә бюджет инвестицияләре бирү тәртибе турында» 2011 елның 14 февралендәге 644 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 6 августындагы
5219 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милек объектларына
бюджет инвестицияләре бирү тәртибе турында
нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 статьясы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре бирү тәртибен һәм күрсәтелгән объектларга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм тормышка ашыру турында карарлар кабул итүне билгели.

2. Бюджет инвестицияләре бирү өчен капиталь төзелеш объектларын, күчемсез милек объектларын сайлап алу Башкарма комитетның муниципаль программа чараларын тормышка ашыру яисә эшчәнлек өлкәсе өчен җаваплы тармак органы тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге үсешенең өстенлекләре һәм максатлары;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш прогнозы;

3) муниципаль программалар;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре;

5) шәһәр бюджетының капиталь салуларга җибәрелә торган акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеген анализлау;

6) капиталь төзелеш объектын төзүнең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең комплекслы үсешенә йогынтысын бәяләү;

7) капиталь төзелеш объектын төзүнең һәм (яки) күчемсез милек объектын сатып алуның конкурентлык мохитенә йогынтысын бәяләү.

3. Бюджет инвестицияләре бирү нәтиҗәсендә төзелгән яки сатып алынган капиталь төзелеш объектлары яки күчемсез милек объектлары билгеләнгән тәртиптә оператив идарә яки хуҗалык алып бару хокукында муниципаль учреждениеләргә беркетелә яисә муниципаль казна составына кертелә.

4. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетын (алга таба – шәһәр бюджеты) үтәгәндә муниципаль милек объектларына капиталь салуларны гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре бирү рөхсәт ителми.

5. Муниципаль милек объектларына бирелә торган бюджет инвестицияләренең күләме муниципаль милекнең капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү) һәм (яки) муниципаль милеккә күчемсез милек объектларын сатып алу максатларында инвестицияләрне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган муниципаль программаларда (алга таба – программалар) тиешле максатлар өчен каралган бюджет ассигнованиеләре күләменә туры килергә тиеш.

Программада каралмаган эшчәнлек юнәлешләре кысаларында, муниципаль милекнең капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләре тормышка ашырылган очракта, муниципаль милек объектларына бирелә торган бюджет инвестицияләренең күләме Башкарма комитет карары белән расланган

Муниципаль милекнең капиталь төзелеш объектлары исемлегендә (алга таба – Исемлек) тиешле максатлар өчен каралган бюджет ассигнованиеләре күләменә туры килергә тиеш.

Исемлекне алып баруны Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе гамәлгә ашыра.

Башкарма комитетның муниципаль программа чараларын тормышка ашыру яисә эшчәнлек өлкәсе өчен җаваплы тармак органы ел саен алдагы хисап елыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр, Исемлеккә кертү өчен, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә әлеге нигезләмәнең 2 пункты нигезендә сайлап алынган бюджет инвестицияләре бирү өчен капиталь төзелеш объектлары, күчемсез милек объектлары турында тәкъдимнәр җибәрә.

6. Бюджет инвестицияләрен муниципаль милек объектларына тормышка ашыру турында карарлар кабул итү сайлап алынган объектларны Программага кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

7. Программада каралмаган эшчәнлек юнәлешләре кысаларында, бюджет инвестицияләрен муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына капиталь салулар формасында тормышка ашыру турында карарлар кабул ителгән очракта, сайлап алынган капиталь төзелеш объектлары Исемлеккә кертелә.

8. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләрен тормышка ашыру Башкарма комитет карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

9. Башкарма комитетның бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм бирү турында карар проектын әзерләү инициаторы булып Башкарма комитетның муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыру яисә әлеге эшчәнлек өлкәсе өчен җаваплы тармак органы тора.

10. Башкарма комитетның бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм тормышка ашыру турында карар проектында түбәндәге мәгълүмат күздә тотыла:

1) капиталь төзелеш объектының яисә күчемсез милек объектының исеме;

2) инвестицияләү юнәлеше (төзелеш (реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементлары белән), техник яктан кораллану, сатып алу);

3) капиталь төзелеш объектын (күчемсез милек объектын) файдалануга тапшыру (сатып алу) срогы;

4) капиталь төзелеш объектының смета бәясе яисә күчемсез милек объектының сатып алу бәясе (тиешле еллар бәяләрендә);

5) бюджет инвестицияләренең гомуми (чик) күләме.

11. Бюджет инвестицияләре белән бәйле чыгымнар объектлар төзү (реконструкцияләү) һәм (яки) сатып алу максатында төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева